СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

22.01.2016 № 11

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законнын 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2016 елда Наласа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә (түләү күләме 350 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Наласа авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш җәю: Наласа авылы,<br>- Яшьләр ур;<br>- Үзәк ур;<br>- Җиңү ур; | <br><br><br>90000<br>90000<br>120000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | - М.Җәлил ур;<br>- М.Вахитов ур.<br>Урта Бирәзә авылы:<br>- Татарстан ур;<br>- М.Вахитов ур. | 60000<br>36000<br><br>30000<br>5000 |
| 2 | Җирләү урыннарын тоту | - Наласа авылында зиратны койма белән тоту | 37200 |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | - Урта Бирәзә авылында чишмә территориясен төзекләндерү | 12000 |
| | | | 480200 |

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов ур., 64 йорт, ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова